**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево – Чертанлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Куакбаш авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләреннән тыш, 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сходнево-Чертанлы авылында Пушкин, Ирек, Кутузов урамнары буйлап юлларны кардан чистарту; Сходнево-Чертанлы авылында Пушкин, Ирек, Кутузов, Горная урамнары буйлап юллардагы чокырларны вак таш белән ремонтлау).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, җирле үзидарә бинасы К.Маркс урамы, 15 йорт; Сходнево-Чертанлы авылы авыл клубы бинасында Ирек урамы, 5б йорт; Чуте авылы авыл клубы бинасында Тынычлык урамы, 8а йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Куакбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова